| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

25.12.2015 Казан ш. № 3330-р

**Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

1. Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең теркәлгән Административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Министр урынбасарларына, идарә башлыкларына хезмәткәрләрне Регламент белән таныштыруны оештырырга һәм аның тайпылышсыз үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының түбәндәге карарларын көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 21 февралендәге, № 433-р (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2013 елның 29 июлендә теркәлгән, теркәлү номеры 1954);

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2013 елның 21 февралендәге 433-р номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 30 июлендәге, № 1564-р (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2014 елның 20 августында теркәлгән, теркәлү номеры 2397).

4. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары С.А.Демидовка йөкләргә.

**Министр в.б. С.А.Демидов**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының
25.12. 2015 ел № 3330-р карары
белән расланды

**Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге Регламент Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: физик яки юридик затлар – Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрендә урнашкан күчемсез мөлкәт объектлары, биналардагы бүлмәләр ияләре (алга таба - күчемсез мөлкәт объектлары ияләре).

Дәүләт хезмәтен алуга гариза бирүчеләр булып дәүләт хезмәтен алучылар яисә дәүләт хезмәтен алучының тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә эш итүче вәкаләтле вәкилләре (алга таба – гариза бирүче) санала.

1.3. Дәүләт хезмәтен Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Министрлык) күрсәтә.

1.3.1. Министрлыкның урнашкан урыны: Казан ш., Вишневский ур., 26 й.

Министрлыкның эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00дән 18.00гә кадәр, җомга – 9.00дән 16.45кә кадәр, төшке аш 11.45тән 12.30га кадәр.

Гариза бирүчеләрдән мөрәҗәгатьләр кабул итү: чәршәмбе 14.00дән 16.00 сәгатькә кадәр.

Җәмәгать транспортында:

№ 1, 4, 25, 43 номерлы автобуслар белән “Калинин” тукталышына кадәр барырга;

метро станциясе – “Сукно бистәсе”.

1.3.2. Министрлыкның Җир ресурслары идарәсенең дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмә алу телефоны: 221-40-39, 221-40-89.

1.3.3. Министрлыкның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендәге (алга таба – Интернет челтәре) рәсми сайты адресы: http://mzio.tatarstan.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәгечә алып була:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст рәвешендәге мәгълүматны эченә алган дәүләт хезмәте турында Министрлык эчендә урнаштырылган мәгълүмат стендларыннан;

2) “Интернет” челтәре ярдәмендә:

Министрлыкның “Интернет” челтәрендәге рәсми сайтыннан (алга таба – рәсми сайт) (http://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru);

Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.tatar.ru);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать итеп (шәхсән яки телефоннан);

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать итеп.

Мәгълүмати стендлардагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 1.3.2, 2.1, 2.3, 2.4, 2,5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктлардагы дәүләт хезмәте турындагы белешмәне үз эченә ала.

1.3.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләләре турында мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтына һәм, гариза бирүчеләр белән эшләү өчен, Министрлык бинасындагы мәгълүмат стендларына урнаштырыла.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге законнар һәм норматив-хокукый актлар нигезендә хәл ителә:

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы (беренче кисәк) (алга таба – РФ ГК 1 к.) (РФ законнары җыелмасы, 05.12.1994, № 32, 3301 ст.) кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ ҖК) (РФ законнары җыелмасы, 29.10.2001, № 44, 4147 ст. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-биреш итүгә хокукларны дәүләт теркәвенә алу турында” 21.07.1997, № 122-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 122-ФЗ Федераль закон) (РФ законнары җыелмасы, 28.07.1997, № 30, ст. 3594) кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында” 25.10.2001, № 137-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 137-ФЗ Федераль закон) (РФ

законнары җыелмасы, 29.10.2001, № 44, 4148 ст. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Күчемсез мөлкәтнең дәүләт кадастры турында” 24.07.2007, № 221-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 221-ФЗ Федераль закон) (РФ законнары җыелмасы, 30.07.2007, № 31, 4017 ст. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып););

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында” 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон) (РФ законнары җыелмасы, 02.08.2010 ел, № 31, 4179 ст. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” 07.05.2012, № 601 Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба – РФ Президенты Указы № 601) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2012, № 19, ст. 2338);

“Гариза бирүченең җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә алу хокукын раслаучы документлар исемлеген раслау турында” 12.01.2015, № 1 Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы (алга таба – Боерык № 1) (“Хокукый мәгълүмат рәсми интернет-порталы” (www.pravo.gov.ru) 28.02.2015);

Татарстан Республикасы Җир кодексы (алга таба – ТР ҖК) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (1 кисәк), 4 ст. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир өчен аренда түләве турында» 1995 елның 9 февралендәге 74 номерлы карары (Известия Татарстана, 14.02.1995, № 28, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 05.12.2005 ел, № 563 карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламенты (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 21.12.2005, № 47-48, 0985 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре” 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 03.10.2007, № 37, 1379 ст. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын

эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 880 ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46, 2144 ст. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында” 13.08.2011, № 675 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 675 ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 19.10.2011, № 39, 1928 ст. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати үзара бәйләнеше тәртибе турында” 07.08.2012, № 674, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати үзара бәйләнеше тәртибе (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 2012, № 59, 2041 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

«Россия Федерациясе Җир кодексының 39.20 статьясы белән күздә тотылган очракларда Татарстан Республикасы милкендәге яки аларга карата дәүләт милке чикләнмәгән, аларда биналар, корылмалар урнашкан җир кишәрлекләрен мондый биналар, корылмалар йә алардагы бүлмәләр милекчеләренә сату турында» 03.10.2012 № 827 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары. (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 09.10.2012, № 75, 2474 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

күпфункцияле үзәкнең дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче ераклаштырылган эш урыны – муниципаль районнардагы авыл җирлекләрендә

документлар кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләрне консультацияләү тәрәзәсе;

техник хата – документларга кертелгән белешмәләрнең (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе) дөреслеккә туры килмәвенә китерүче министрлык хатасы (язудагы хата, ялгыш басылу, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать (алга таба – мөрәҗәгать) - 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүне сорау. Мөрәҗәгатьнең киңәш ителгән формасы әлеге Регламентның 1 кушымтасында китерелгән.

**2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты**

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка таләпнең эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү | РФ ГК; РФ ҖК; Федераль закон № 137-ФЗ; ст. ст.4,18 ТР ҖК п. 3.3.19 Нигезләмә |
| 2.2. Башкарма хакимиятнең дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче органы атамасы | Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | п. 3.3.19 Нигезләмә |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе тасвирламасы | Җир кишәрлеген арендага алу шартнамәсе.<br>Җир кишәрлеген сату-алу шартнамәсе.<br>Җир кишәрлеген милек итеп яисә арендага бирүдән баш тарту турында карар. | Ст.39.6 РФ ҖК,<br>ст. 39.3 РФ ҖК,<br>ст. 39.14 РФ ҖК,<br>ст. 39.20 РФ ҖК |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучыларның оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып | Дәүләт хезмәте мөрәҗәгать кергәннән соң, гариза бирүченең җир кишәрлеген арендалау (сату-алу) шартнамәсен имзалау срогын да кертеп, алтмыш көн эчендә күрсәтелә | ст. 39.17 РФ ҖК |
| 2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне | Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү өченгариза бирүче мөрәҗәгать (1 нче кушымта) | Боерык № 1 |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, гариза бирүченең аны алу ысуллары, аларны бирү тәртибе | белән бергә түбәндәгеләрне тапшыра:<br>1. Гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, физик яки юридик зат вәкиленең хокукларын (вәкаләтләрен) раслаучы документ күчермәсе.<br><br>2. Гариза бирүченең бинага, корылмага булган хокуклары Күчемсез милек һәм аның белән алыш-бирешкә хокуклар бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән булса (алга таба - ХБДР), аның бинага, корылмага хокукын раслаучы (билгеләүче) документ күчермәсе.<br><br>3. Гариза бирүченең соралган җир кишәрлегенә хокуклары ХБДРда теркәлмәгән булса, аның җир кишәрлегенә булган хокукын раслаучы (билгеләүче) документ күчермәсе.<br><br>4. Гариза бирүченең соралган җир кишәрлегендә урнашкан бөтен биналар, корылмаларның, кадастр номерлары (шартлы, инвентарь) һәм адрес ориентирлары күрсәтелгән исемлеге җир кишәрлеге бирү турында мөрәҗәгатьнең тәкъдим ителгән кушымтасындагы формада бирелгән белдерүе.<br>Гариза бирүче (бинадагы бүлмәнең милекчесе) җир | |

| | | |
|---|---|---|
| | кишәрлеге милек итеп бирелгәндә, өстәмә рәвештә, әгәр хокукы ХБДРда теркәлмәгән булса, бүлмәгә булган хокукын раслаучы документ күчермәсен дә бирә<br>Беркетелгән документлар нотариуста яки документның оригиналын биргән органда (оешма, учреждение) расланмаган булса, документларның копияләре төп нөсхә белән бергә бирелә һәм аларны Министрлык белгече раслый. | |
| 2.6. Норматив хокукый актларга туры китереп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм башка оешмаларда сакланган, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар сакланган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысасында алыналар:<br><br>1. Соралган җир кишәрлегенең кадастр паспорты яисә соралган җыр кишәрлеге турында кадастр өземтәсе («Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалыннан).<br>2. Алынучы җир кишәрлегендә урнашкан биналар, корылмаларның кадастр паспорты (“Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте” федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы филиалыннан).<br>3. Соралган җир кишәрлегендә урнашкан бинада, корылмадагы бүлмәнең милекчесе мөрәҗәгать иткән | Ст.39.17 РФ ЖК;<br>Боерык № 1;<br>ТР МК карары № 675 |

| | | |
|---|---|---|
| | очракта, бүлмәнең кадастр паспорты («Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалыннан).<br>4. Алына торган җир кишәрлеге һәм анда урнашкан күчемсез объектларына хокук турында Күчемсез милек һәм аның белән алыш-бирешкә хокуклар бердәм дәүләт реестрыннан өземтә яисә ХБДРда соралга мәгълүматның булмавы турында белдерү (алга таба – ХБДР) («Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән).<br>5. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан гариза бирүче булган юридик зат турында өземтә (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән).<br>6. Гариза бирүче турында Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән).<br>Гариза бирүче алда күрсәтелгән документларны үзе дә китерә ала.<br>Гариза бирүче алда күрсәтелгән документларны китермәве дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен | |

| | | |
|---|---|---|
| | нигез булып тормый. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен таләп ителгән һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма орган тарафыннан тормышка ашырыла торган норматив-хокукый актларда каралган очракларда килештерү зарури булган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Мөрәҗәгать РФ ҖКның 39.17 статьясындагы беренче пунктындагы нигезләмәләргә туры килми, башка вәкаләтле органга тапшырылган яисә мөрәҗәгатькә әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар беркетелмәгән.<br>2. Мөрәҗәгатьтә һәм аңа беркетелгән документларда тиешле тәртиптә расланмаган чистартулар, өстәп язулар булу | Ст.39.17 РФ ҖК;<br>Боерык № 1 |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр законда каралмаган.<br>Үтенечнамәне караудан баш тарту өчен нигезләр:<br>1. Гариза бирүче тапшырган документларда дөрес булмаган мәгълүмат булу.<br>2. Регламентның 3 нче кушымтасына туры китереп | ст.39.16 РФ ҖК;<br>Боерык № 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләүнең тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы алынучы түләүләрнең тәртибе, күләме һәм нигезләре, андый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри дәүләт хезмәтләре түләүсез күрсәтелә. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәтләрне күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы | Дәүләт хезмәте алучының (гариза бирүченең) кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүенең һәм дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәтен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | РФ Президенты Указы № 601, п. 1 |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап гариза бирүченең запросын рәсмиләштерү срогы | Мөрәҗәгать һәм документлар кергән көндә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтеп тору һәм кабул ителү урыннарына, шул исәптән, Россия Федерациясенең | Дәүләт хезмәтләре күрсәтелү тиешле күрсәткечләр белән җиһазланган бүлмәләрдә башкарыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелүчеләр әлеге максатлар өчен бүлеп бирелгән,<br>һаваны суыту-җылыту системасы; | |

| | | |
|---|---|---|
| инвалидларны социаль яклау турында законнарына туры китереп әлеге объектларның инвалидлар керә алырлык булуын тәэмин итүгә карата, хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиалы мәгълүматка таләпләр | янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы;<br>документлар тутыру өчен җиһаз;<br>Татарстан Республикасы Интеграцияләнгән дәүләт телекоммуникация системасына тоташтырылган мәгълүмати киоск;<br>мәгълүмати стенд белән җиһазландырылган,<br>инвалидлар каршылыксыз керә ала торган чаралар һәм җайланмалар белән җиһазландырылган урыннарда башкарыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән, гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнеше саны һәм аның вакыт буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгендә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкләрнең ераклаштырылган эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтелү | Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Министрлык биналарының җәмәгать транспортына якын булуы;<br>Министрлык бинасын һәм бүлмәләрне инвалидлар дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга каршылыксыз керә ала торган чаралар һәм җайланмалар белән тәэмин итү;<br>кирәк кадәр санда белгечләрнең, шулай ук, гариза бирүчеләрнең документларын кабул итә торган урыннарның булуы;<br>мәгълүмати стендларда һәм “Интернет” челтәрендә, рәсми сайтта (http://mzio.tatarstan.ru) дәүләт хезмәте күрсәтүнең ысуллары, тәртибе һәм вакыты турында тулы мәгълүмат булу. | |

| | | |
|---|---|---|
| барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән, мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне кулланып | Дәүләт хезмәтенең сыйфаты күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау срогының саклануы;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогының саклануы;<br>әлеге регламентның Министрлык белгечләре тарафыннан бозылуын күрсәткән очракларның (нигезләнгән шикаятьләрнең) булуы;<br>гариза бирүченең министрлык белгечләре белән үзара бәйләнеш саны:<br>гариза бирүче шәхсән үзе мөрәҗәгать иткән очракта министрлык белгечләре белән үзара бәйләнеше бер тапкырдан (консультацияләрне исәпкә алмаганда) да артык түгел.<br>Мөрәҗәгатьне һәм документларын почта аша җибәргәндә – (консультацияләрне исәпкә алмаганда) бердән дә артык түгел.<br>Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче белгеч белән үзара бәйләнеше вакыты 15 минуттан да артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелү барышы турындагы мәгълүматны гариза бирүче рәсми сайттан (http://mzio.tatarstan.ru), Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) алырга мөмкин. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Дәүләт хезмәте күп функцияләр башкаручы үзәктә, күп функцияләр башкаручы үзәкнең дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган ераклаштырылган эш урыннарында күрсәтелми. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтелми | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларның (гамәлләрнең) электрон рәвештә үтәлүе үзенчәлекләре, шулай ук, административ процедураларның күпфункцияле үзәкләрдә, күп функцияле үзәкләрнең дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча ераклаштырылган эш урыннарында

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы

3.1.1. Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар тутыру буенча да;

үтенечнамәне һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау

Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү турында министрлык карары проекты яисә бир кишәрлеген сатып алу шартнамәсе проекты яки җир кишәрлеген арендага яки милеккә бирүдән баш тарту турында карар проекты әзерләү

Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы 4 нче кушымтада китерелә.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, дәүләт хезмәте тутыру өчен кирәкле документлар тутыру буенча да.

Гариза бирүче, дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Бүлеккә шәхсән, телефоннан, һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итүгә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә, аның нинди ысул белән мөрәҗәгать итүенә карап, шәхсән үзенә, телефоннан, электрон почта аша һәм (яки) хат белән консультация бирә, шул исәптән тапшырылырга тиешле документларның составы, формасы ягыннан һәм дәүләт хезмәте алуга карата башка мәсьәләләр

буенча, гариза бирүчегә ярдәм итә, шул исәптән, дәүләт хезмәте тутыру өчен кирәкле документлар тутыру буенча да.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне (гариза теркәлгән көн) үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: консультация, шулай ук, күрсәтелгән ярдәм, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларны тутырырга булышу.

3.3. Мөрәҗәгатьне кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар беркетелгән мөрәҗәгатен Министрлыкка бирә

Мөрәҗәгать һәм документларның нотариус яки документ оригиналын биргән орган (оешма, учреждение) раслаган күчермәсе почта аша юллана ала.

3.3.2. Эш башкару бүлеге белгече:

мөрәҗәгатьне һәм документларны кабул итә;

мөрәҗәгатьне һәм документларны кабул итмәү өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигез булу-булмавын тикшерә. Тикшерү Бүлек белгече катнашында башкарыла;

әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигез булмаган очракта мөрәҗәгатьне һәм беркетелгән документларны теркәп, карау өчен Бүлеккә юллый.

әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигез булган очракта документларны теркәмичә генә, Бүлек белгече әзерләгән, документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләре күрсәтелгән аңлатма белән бергә, гариза бирүчегә кайтара.

Әлеге пункт билгеләгән процедура мөрәҗәгать һәм документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Бүлеккә юлланган мөрәҗәгать; гариза бирүчегә кайтарылган документлар.

3.4. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашкан органнарга юллау

3.4.1. Бүлек белгече мөрәҗәгатьне һәм документларны эш башкару бүлегеннән алганнан соң “ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында җир кишәрлеге бирү турында гаризалар үтү бите”н (2 нче кушымта) тутыра, ведомоствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон формада запрослар юллый:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан гариза бирүче булган юридик зат турында мәгълүмат бирүне сорап Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә (алга таба – ФСХ ТРИ)

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенә (алга таба – Росреестр ТРИ) – алынасы җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылма, бинадагы бүлмәгә хокук турында (күрсәтелгән бинага, корылмаларга теркәлгән хокуклар турында мәгълүмат булмавына ХБДРдан өземтә) бирү турында;

ТР буенча Росреестрга соралган җир кишәрлегенә хокуклар турында ХБДРдан өземтә бирү турында;

«Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына соралган җир кишәрлегенең кадастр паспортын бирү турында.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң дүрт көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүматлар (документлар) бирү турындагы запрослар

3.4.2. Ведомствоара хезмәттәшлек органнары белгечләре 3.4.1 пунктта ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән алда күрсәтелгән запрослар нигезендә тиешле срокларда соралган документларны (мәгълүматны) бирәләр.

Процедуралар нәтиҗәсе: запросларга җавап нәтиҗәсе булып торган мәгълүмат (документлар), яисә, баш тарту турында министрлыкка юлланган белдерү кәгазе.

3.5. Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү турында министрлык карары проекты (алга таба - арендага (милеккә) бирү турында карары проекты)  һәм җир кишәрлеген арендага (сату-алу) шартнамәсе проекты яки җир кишәрлеген арендага яки милеккә бирүдән баш тарту турында карар проекты (баш тарту турында карар проекты) әзерләү

3.5.1. Бүлек белгече әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар (документлар) алынгач түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булуын тикшерә;

арендага (милеккә) бирү турында карары проектын һәм җир кишәрлеген арендага (сату-алу) шартнамәсе проектын, аренда (сату-алу) шартнамәсе проекты белән бергә җибәрелә торган хатны, яисә баш тартуга нигезләрне һәм ачыкланган кимчелекләрне бетерү тәкъдимнәре булган баш тарту турында карар проекты әзерләнә;

арендага (милеккә) бирү турында карары проектын һәм җир кишәрлеген арендага (сату-алу) шартнамәсе проектын, яисә баш тарту турында карар проектын килештерү өчен Бүлек мөдиренә юллау.

Бу пункт билгели торган процедуралар запросларга җавап алынганнан соң биш көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: килештерү өчен Бүлек мөдиренә юлланган арендага (милеккә) бирү турында карары проекты һәм җир кишәрлеген арендага (сату-алу) шартнамәсе проекты, яисә баш тарту турында карар проекты.

3.5.2. Бүлек мөдире арендага (милеккә) бирү турында карары проектын һәм җир кишәрлеген арендага (сату-алу) шартнамәсе проектын, яисә баш тарту турында карар проектын карый, килештерә һәм килештерү өчен җир ресурслары идарәсе (алга таба – Идарә) башлыгына юллый.

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек мөдире белән килештерелеп, килештерү өчен Идарә башлыгына юлланган арендага (милеккә) бирү турында карары проекты һәм җир кишәрлеген арендага (сату-алу) шартнамәсе проекты, аренда (сату-алу) шартнамәсе проекты белән бергә җибәрелә торган хат, яисә баш тарту турында карар проекты.

3.5.3. Идарә башлыгы арендага (милеккә) бирү турында карары проектын һәм җир кишәрлеген арендага (сату-алу) шартнамәсе проектын, аренда (сату-алу) шартнамәсе проекты белән бергә җибәрелә торган хатны яисә баш тарту турында карар проектын карый, килештерә һәм Бүлек белгеченә юллый.

Әлеге Регламентның 3.5.2, 3.5.3 пунктлары билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң өч көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек мөдире, Идарә башлыгы белән килештерелгән арендага (милеккә) бирү турында карары проекты һәм җир кишәрлеген арендага (сату-алу) шартнамәсе проекты, аренда (сату-алу)

шартнамәсе проекты белән бергә җибәрелә торган хат, яисә баш тарту турында карар проекты.

3.5.4. Бүлек белгече Бүлек мөдире, Идарә башлыгы белән килештерелгән арендага (милеккә) бирү турында карары проектын һәм җир кишәрлеген арендага (сату-алу) шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын хокукый экспертиза өчен хокук идарәсенә юллый.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек мөдире, Идарә башлыгы белән килештерелеп, Хокук идарәсенә юлланган арендага (милеккә) бирү турында карары проектын һәм җир кишәрлеген арендага (сату-алу) шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проекты.

3.5.5. Хокук идарәсе белгече арендага (милеккә) бирү турында карары проектына һәм җир кишәрлеген арендага (сату-алу) шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектына хокукый экспертиза (шул исәптән, проектның антикоррупцион экспертизасын) ясый, килештерә һәм хокук идарәсе башлыгына арендага (милеккә) бирү турында карары проектын һәм җир кишәрлеген арендага (сату-алу) шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын – килештерү өчен яисә, арендага (милеккә) бирү турында карары проектына һәм җир кишәрлеген арендага (сату-алу) шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектына кисәтүләр булган очракта, хокук идарәсе бәяләмәсе проектын  имзалау өчен юллый.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң ике көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: арендага (милеккә) бирү турында карары проектына һәм җир кишәрлеген арендага (сату-алу) шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектына кисәтүләр булган очракта, хокук идарәсе бәяләмәсе проекты, яисә килештерелгән арендага (милеккә) бирү турында карары проектына һәм җир кишәрлеген арендага (сату-алу) шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проекты.

3.5.6. Хокук идарәсе башлыгы арендага (милеккә) бирү турында карар проектын һәм җир кишәрлеген арендага (сату-алу) шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын килештерә яисә хокук идарәсе бәяләмәсен имзалый һәм Бүлек белгеченә юллый.

Бу пункт билгели торган процедуралар запросларга җавап алынганнан соң ике көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: хокук идарәсе бәяләмәсе яисә килештерелгән арендага (милеккә) бирү турында карар проектын һәм җир кишәрлеген арендага (сату-алу) шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проекты.

3.5.7. Бүлек белгече хокук идарәсе бәяләмәсен алган очракта кимчелекләрне төзәтә һәм арендага (милеккә) бирү турында карар проектын һәм җир кишәрлеген арендага (сату-алу) шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын Хокук идарәсе башлыгына килештерергә юллый.

3.5.8. Хокук идарәсе башлыгы хокук идарәсе бәяләмәсендә күрсәтелгән кимчелекләрнең төзәтелү фактын тикшерә һәм проектны килештерә.

Әлеге Регламентның 3.5.7, 3.5.8 пунктлары билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң ике көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: Хокук идарәсе башлыгы белән килештерелгән, Бүлек белгеченә юлланган арендага (милеккә) бирү турында карар проекты һәм җир кишәрлеген арендага (сату-алу) шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты.

3.5.9. Бүлек белгече хокук идарәсе башлыгы белән килештерелгән арендага бирү турында карар проектын яисә баш тарту турында карар проектын, аренда шартнамәсе проектын, аренда шартнамәсе проектына кушып җибәрелә торган хатны министрның беренче урынбасарына - имзалау өчен, милеккә бирү турында карар проектын килештерергә юллый.

Бу пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланган көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Министрның беренче урынбасарына юлланган арендага (милеккә) бирү турында карар проекты, аренда шартнамәсе проекты, аренда шартнамәсе проектына кушып җибәрелә торган хат проекты, яисә баш тарту турында карар проекты.

3.5.10. Министрның беренче урынбасары җир кишәрлеген арендага бирү турында Министрлык карарына, аренда шартнамәсе проектына, аренда шартнамәсе проектына кушып җибәрелә торган хат проектына, яисә баш тарту турында карар проектына кул куя һәм теркәү өчен эш башкару бүлегенә юллый, яисә милеккә бирү турында карар проектын килештерә һәм имзалау өчен министрга юллый.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Министрның беренче урынбасары имзалаган һәм теркәү өчен эш башкару бүлегенә юлланган җир кишәрлеген арендага бирү турында Министрлык карары, яисә баш тарту турында карар проекты, аренда шартнамәсе проекты, аренда шартнамәсе проектына кушып җибәрелә торган хат проекты, яисә милеккә бирү турында килештерелгән һәм имзалау өчен министрга юлланган карар проекты.

3.5.11. Министр җир кишәрлеген милеккә бирү турында Министрлык карарына кул куя һәм министрның беренче урынбасарына юллый.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: җир кишәрлеген сату-алу турында имзаланган һәм министрның беренче урынбасарына юлланган Министрлык карары.

3.5.12. Министрның беренче урынбасары сату-алу турында шартнамә проектына, сату-алу турында шартнамә проектына кушып җибәрелә торган хат проектына кул куя һәм җир кишәрлеген милеккә бирү турында Министрлык карары белән бергә теркәү өчен эш башкару бүлегенә юллый.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Министрның беренче урынбасары кул куйган һәм җир кишәрлеген милеккә бирү турында Министрлык карары белән бергә теркәү өчен эш башкару бүлегенә юлланган сату-алу турында шартнамә проекты, сату-алу турында шартнамә проектына кушып җибәрелә торган хат проекты.

3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен гариза бирүчегә тапшыру.

3.6.1. Эш башкару бүлеге белгече җир кишәрлеген арендага яки милеккә бирү турында Министрлык карарын яисә баш тарту турында карарны, аренда (сату-алу) шартнамәсенә кушып җибәрелә торган хат проектын терки, гариза бирүчегә арендага яки милеккә бирү турында Министрлык карарын яисә баш тарту турында карарны алырга килү өчен билгеләнгән вакыт турында хәбәр итә, яисә арендага яки милеккә бирү турында Министрлык карарын яисә баш тарту турында карарны гариза бирүче күрсәткән почта адресы буенча юллый. Министрлыкның җир кишәрлеген арендага (милеккә) алу турында карарын эш башкару бүлеге белгече Бүлеккә юллый.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: эш башкару бүлегендә теркәлгән һәм Бүлеккә юлланган - җир кишәрлеген арендага (милеккә) бирү турында Министрлык карары; гариза бирүчегә юлланган – баш тарту турында карар яисә кушып җибәрелә торган хаты белән бергә аренда (сату-алу) шартнамәсе проекты.

3.6.2. Гариза бирүче аренда (сату-алу) шартнамәсе проекты, баш тарту турында карарны алырга килгәндә эш башкару бүлегенең документларны тапшыру өчен җаваплы белгече түбәндәгеләрне башкара:

вәкилнең шәхесен ачыклый, шул исәптән шәхесен раслаучы документны тикшерә; вәкилнең вәкаләтләрен (боерык, ышанычнамә) аныклый

аренда (сату-алу) шартнамәсе проектын яки баш тарту турында карарны гариза бирүчегә тапшыра һәм исәпкә алу кенәгәсенә документларны бирү турында язып куя.

Әлеге пункт билгели торган процедура вәкил килгән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән аренда (сату-алу) шартнамәсе проектын яки баш тарту турында карар.

3.6.3. Гариза бирүче алганнан соң утыз календарь көне эчендә аренда (сату-алу) шартнамәсенә кул куя һәм Министрлыкка аренда (сату-алу) шартнамәсен китереп бирә.

3.6.4. Министрлыкның беренче урынбасары һәм гариза бирүче кул куйган аренда (сату-алу) шартнамәсе Министрлыкның Исәпләү, мониторинг һәм мәгълүмати хезмәттәшлек идарәсенең Татарстан Республикасының дәүләт милке реестры бүлегендә теркәлә һәм гариза бирүчегә юллана.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: теркәлгән һәм гариза бирүчегә юлланган аренда (сату-алу) шартнамәсе.

Дәүләт хезмәте электрон формада, күпфункцияле үзәкләр, күпфункцияле үзәкләрнең дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган ераклаштырылган эш урыны аша күрсәтелми.

3.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән техник хаталарны төзәтү:

Гариза бирүченең аренда (сату-алу) шартнамәсендә киткән техник хатаны төзәтү буенча мөрәҗәгате Министрлык тарафыннан техник хатаны төзәтелүенә нигез булып тора.

3.8.1. Техник хатаны төзәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүче түбәндәгеләрне бирә:

техник хаталарны төзәтү турында мөрәҗәгать (5 нче кушымта);

җир кишәрлеген арендалау яки сату-алу шартнамәсенең төп нөсхәсе;

Техник хатаның булуын дәлилләгән документлар.

3.8.2. Техник хатаны төзәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгатьне гариза бирүче Министрлыкка тапшыра яисә почта аша юллый.

3.8.3. Эш башкару бүлеге белгече мөрәҗәгатьне кабул итеп ала һәм, беркетелгән документлары белән бергә, теркәп, Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пункт билгели торган процедура мөрәҗәгать һәм документлар кергән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Карау өчен Бүлек белгеченә юлланган мөрәҗәгать.

3.8.4. Бүлек белгече документларны карап чыга һәм җир кишәрлеген арендага (милеккә) бирү турында шартнамәгә үзгәрешләр кертү максатыннан (техник хаталарны төзәтү) арендага (милеккә) бирү турында карарга һәм арендага (милеккә) бирү турында шартнамәгә үзгәрешләр кертү турында акт проекты әзерли һәм әлеге Регламентның 3.5.2, 3.5.3, 3.5.9-3.5.12, 3.6.1, 3.6.2 пунктларында каралган процедураларны күрсәтелгән тәртиптә гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура техник хата табылганнан соң яисә теләсә кайсы кызыксынган заттан хата җибәрелү турында мөрәҗәгать алган көннән соң биш көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: арендага (милеккә) бирү турында карарга үзгәрешләр кертү, арендага (милеккә) бирү турында шартнамәгә үзгәрешләр проектының гариза бирүчегә юллануы.

3.9. Техник хатаны төзәтүгә кагылышлы документларны (беркетелгән документлар белән бергә техник хатаны төзәтү турында мөрәҗәгать, арендага (милеккә) бирү турында карарга үзгәрешләр кертү (техник хаталары төзәтелеп) Бүлек белгече аренда (сату-алу) шартнамәсенең Министрлыкта калган нөсхәсенә беркетә.

## 1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедуралар белән

билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге саклануын дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Идарә (бүлек) җитәкчесе әлеге Регламент нигезләмәләрен үтәү һәм башкаруны күзәтү юлы белән контрольдә тота.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне Министрлыкның вазыйфаи затлары контрольдә тота. Контрольдә тотучы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык идарәләре (бүлекләре) турында нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту тикшерүләр үткәрүне, гариза бирүчеләрнең дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затларның кылган (кылмаган) гамәлләре турында шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләрен карап, карарлар кабул итүне һәм гариза бирүченең мөрәҗәгатенә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәге тикшерүләр тора:

эш башкаруны алып бару;

документлар карау нәтиҗәләренең закон таләпләренә (әлеге Регламентка) туры килүе;

документлар кабул итү срокларын һәм тәртибен саклау;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр бирү срогы һәм тәртибе саклану.

Тикшерүләр планлы (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин (гариза бирүченең мөрәҗәгате буенча).

4.3. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законы нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контрольдә тоту Идарә эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәтүдәге ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 1. Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү

5.1. Гариза бирүчеләр Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата шикаять белдерүгә хокуклы.

Министрның карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә

Министр урынбасарының, дәүләт хезмәткәренең карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять министр исеменә бирелә.

5.2. Шикаять язмача кәгазьдә яисә электрон формада бирелә.

5.3. Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең ераклаштырылган эш урыны аша, рәсми сайт (http://mzio.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталы (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

5.5. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш::

1) карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять белдерелгән Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булганда), яшәү урыны турында мәгълүматлар, мөрәҗәгать итүче юридик затның урнашкан урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүченең Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре белән килешмәвенә дәлилләре. Гариза бирүче үз дәлилләрен раслый торган документлар (булганда) яки аларның күчермәләрен тапшыра ала.

5.6. Министрлыкка кергән шикаять шикаятьләрне карап тикшерүгә вәкаләте булган вазыйфаи зат тарафыннан шикаять теркәлгән көннән алып унбиш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш, Министрлык, аның вазыйфаи заты гариза бирүчедән документларын кабул итеп алудан баш тартуга яки ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуга яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерелгән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.7. Министрлык шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан кабул ителгән карарны юкка чыгару рәвешендә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда Министрлык

тарафыннан җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акча средстволарын гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

5.8. Әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм, гариза бирүченең теләгенә карап, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаятьләрнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында карап тикшерү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

5.10. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча, административ хокук бозу билгеләре яки җинаять ачыкланса, шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны тиз арада прокуратура органнарына юллый.

**Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына 1 нче кушымта**

Тәкъдим ителгән форма

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына
___________________

Җир кишәрлеге бирү турында гариза

_____________________________________________________________
(юридик затның исеме яки (физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме) яисә
_____________________________________________________________,
вәкиле)
____________________________________________нигезендә эш итүче,
(вәкил мөрәҗәгать иткәндә - вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ)

__________________________________ кадастр номеры белән җир кишәрлеге бирүегезне сорыйм (сорый),
_________________________________________________ хокукында
(хокук атамасы күрсәтелә: милек яки аренда)
Россия Федерациясе Җир кодексы [*] _________________) нигезендә

_____________________________________________________ өчен.
(җир кишәрлеген файдалану максаты күрсәтелә)

| Гариза бирүче турында мәгълүмат (гариза бирүчеләр) | |
|---|---|
| Юридик зат реквизитлары *(ОГРН, ИНН, адрес (урнашкан урыны)* | |
| | |
| | |
| Физик зат өчен (юридик затның вәкиле) паспорт мәгълүматлары *(серия, номер, кем кайчан биргән,* | |

[*] Җир кишәрлеген торгларсыз бирү нигезләре күрсәтелә: Россия Федерациясенең Җир Кодексының 39.3 статьясының 2 пункты 6 подпункты (җир кишәрлеген анда урнашкан биналар, корылмаларның яисә андый биналардагы бүлмәләрнең милекчеләренә сату) яисә Россия Федерациясенең Җир Кодексының 39.6 статьясының 2 пункты 9 подпункты (җир кишәрлеген анда урнашкан биналар, корылмаларның яисә андый биналардагы бүлмәләрнең милекчеләренә арендага бирү)

| | |
|---|---|
| *подразделение коды, теркәлү адресы),* Яшәгән адресы (теркәлү адресы белән туры килмәгән очракта), ИНН | |
| Телефон, почта адресы һәм (яисә) электрон почта адресы | |
| Җир кишәрлеге турында мәгълүмат | |
| Җир кишәрлеген бирүнең алдан килештерелүе турында карарның реквизитлары (җир кишәрлеге яңадан ясалган яисә аның чикләре әлеге карар нигезендә аныкланган булса) | |

“Персональ мәгълүматлар турында” 27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль законга туры китереп, мин 420043, ТР, Казан ш., Вишневский ур., 26 й. Адресында урнашкан Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына (оператор) персональ мәгълүматны эшкәртергә (әлеге гаризада күрсәтелгән персональ мәгълүматны җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, аныклауны (яңарту, үзгәртү), файдалану, тапшыру (тарату, бирү), блоклауны, бетерүне, юкка чыгаруны да кертеп, автоматлаштыру чаралары белән яки алардан башка кылынган гамәл (операция) яисә гамәлләр (операцияләр) белән эшкәртергә рөхсәт бирәм. Мәгълүматның дөреслеген раслыйм.

Әлеге килешү гариза имзаланган көннән башлап язма рәвештә килешүне кире соратып алган көнгә кадәр гамәлдә була.

Гариза бирүченең имзасы (_______№__________________________ышанычнамә буенча вәкил
__________________________________________/________________________/
(вәкилнең фамилия, имя, әтисе исеме, имзасы)

М.П. (мөһер булганда)

Гариза кабул ителде: "___"__________ 20__ г.
______/__________________/гаризаны алган белгечнең имзасы, фамилиясе, инициаллары)

Искәрмә. Персональ мәгълүматларны эшкәртү турында ризалык физик зат яисә аның вәкиле исеменнән бирелә. Физик затның вәкиле ризалык биргәндә: вәкилнең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, адресы, аның шәхесен раслаучы төп документының номеры, бирелгән датасы һәм биргән орган күрсәтелә, вәкилнең вәкаләтләрен раслаган ышанычнамә яисә башка документның реквизитлары бирелә.

**Җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатькә кушымта**

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына

______________________ кадастр номерлы җир кишәрлегендә урнашкан объектларның исемлеге

| Күчемсез объект(лар)ның атамасы | Күчемсез объект(лар)ның кадастр (инвентарь) номеры | Күчемсез объект(лар)ның адрес ориентирлары |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |

Җир кишәрлегендәге, ______________________________ адресы белән урнашкан _________________ га мәйдандагы барлык биналар һәм корылмалар әлеге вакытта ______________________________________________________________________ милке булып тора

(оешманың атамасы)

_____________________________________________, өченче затларның хокуклары һәм претензияләре юк

Җир кишәрлегендә булган, башка юридик (физик) затларның милке саналган (хуҗалык алып баруы, оператив идарәдә) күчемсез объектлар:

Бар (хокукы булганнар) __________________________________________________

юк

җир кишәрлегендә урнашкан мобилизация билгеләнешендәге һәм гражданлык оборонасы объектлары:

бар (санап үтәргә): ____________________________________________________________

юк

Җитәкче ___________________________ фамилия, инициаллар

Искәрмә. Юридик зат мөрәҗәгать иткәндә юридик затның мөһере (булган очракта) кирәк.

**Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына 2 нче кушымта**

ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында җир кишәрлеге бирү турында мөрәҗәгатьнең үтү бите

Гариза керү датасы «_____»_____________
Гариза бирүче ____________________________________________________
Теркәү (кергән) номеры ____________________________

| /п | Министрлыкның структур бүлекчәсе | Алу датасы | Имза | Тапшыру датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Эш башкару һәм контроль бүлеге | | | | |
| 2. | Җир ресурслары идарәсенең дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге белгече | | | | |
| | Килештерүләр: | | | | |
| 3. | Җир ресурслары идарәсенең дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге мөдире | | | | |
| 4. | Җир ресурслары идарәсе башлыгы | | | | |
| 5. | Хокук идарәсе белгече | | | | |
| 6. | Хокук идарәсе мөдире | | | | |
| 7. | Министрның беренче урынбасарының кабул итү бүлмәсе (документларны имзалау) | | | | |
| 8. | Министрның кабул итү бүлмәсе (документларны имзалау) | | | | |
| 9. | Эш башкару һәм контроль бүлеге (документларны рәсмиләштерү һәм теркәү) | | | | |

**Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына 3 нче кушымта**

## Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр

1) җир кишәрлеге бирү турында җир законнары буенча җир кишәрлеген торгларсыз алырга хокукы булмаган зат мөрәҗәгать итә;

2) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану, түләүсез файдалану, гомерлеккә мирас ителгән биләмәләр яки аренда хокукында бирелгән; җир кишәрлеге бирү турында гариза белән әлеге хокуклары булган кеше мөрәҗәгать итүе яисә җир кишәрлеге бирү турында гаризаның РФ ҖКның 39.10 статьясының 2 пункты 10 подпунктына туры китереп бирелгән булуы чыгарма булып тора.

3) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге яшелчәчелек, бакчачылык, дача хуҗалыгы яки индивидуаль торак төзелеше максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциячел булмаган оешмаларга бирелгән; әлеге коммерциячел булмаган оешманың әгъзасы яисә, җир кишәрлеге гомуми файдаланыла торган милеккә кергән очракта, әлеге коммерциячел булмаган оешма гариза белән мөрәҗәгать иткән очраклар чыгарма булып тора;

4) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлегендә гражданнарга яки юридик затларга караган биналар, корылмалар, төзелеп бетмәгән объектлар урнашкан; корылма (шул исәптән, төзелеп бетмәгән корылма) җир кишәрлегендә сервитут шартларында урнашкан очраклар яки җир кишәрлегендә РФ ҖКның 39.36 статьясының 3 пунктында каралган объект урнаштырылган һәм ул җир кишәрлеген рөхсәт ителгәнчә файдаланырга комачауламый, яисә җир кишәрлеген үзенә бирү турындагы

гариза белән әлеге бинаның, корылманың, төзелеп бетмәгән объектның хосусый милек иясе мөрәҗәгать иткән очраклар чыгарма булып тора;

5) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлегендә дәүләти яки муниципаль милек булган биналар, корылмалар, төзелеп бетмәгән объектлар урнашкан; корылма (шул исәптән, төзелеп бетмәгән корылма) җир кишәрлегендә сервитут шартларында урнашкан очраклар яисә җир кишәрлеген үзенә бирү турындагы гариза белән әлеге бинаның, корылманың, төзелеп бетмәгән объектка хокукы булган зат мөрәҗәгать иткән очраклар чыгарма булып тора;

6) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге әйләнештән алынган булса яисә әйләнеше чикләнгән булып, җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән хокук буенча бирергә ярамый;

7) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләт ихтыяҗларына резервка куелган булып, гариза бирүче җир кишәрлеген милек итеп даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга яисә җир кишәрлеген арендага җир кишәрлеген резервка кую турында карар гамәлдә булганнан озаграк вакытка түләүсез файдалануга бирү турында мөрәҗәгать итсә; җир кишәрлеген резервка кую максатыннан бирү чыгарма булып тора;

8) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге төзелгән территориянең үсеше турында башка зат белән шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан; җир кишәрлеген үзенә бирү турындагы гариза белән шушы җир кишәрлегендә урнашкан бинаның, корылманың, төзелеп бетмәгән объектның хосусый милек иясе яки әлеге җир кишәрлегенә хокукы булган зат  мөрәҗәгать иткән очраклар чыгарма булып тора;

9) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге төзелгән территориянең үсеше турында башка зат белән шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан, яисә җир кишәрлеге башка зат белән территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән ясалган; җир кишәрлеге федераль әһәмияткә ия объектлар, региональ әһәмияткә ия объектлар яки җирле әһәмияткә ия объектларны урнаштыруга билгеләнгән булып, җир кишәрлеген бирү турында әлеге объектларны төзергә вәкаләтле затның мөрәҗәгате чыгарма булып тора.

10) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге башка зат белән территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә яисә төзелгән территориянең үсеше турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән ясалган һәм территориянең планы буенча расланган документациягә ярашлы рәвештә федераль әһәмияткә ия объектлар, региональ әһәмияткә ия объектлар яки җирле әһәмияткә ия объектларны урнаштыруга билгеләнгән; җир кишәрлеген арендага алу турында гариза белән территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә яисә төзелгән территориянең үсеше турында шартнамә төзелгән һәм әлеге объектларны төзү йөкләмәсе булган затның мөрәҗәгать итүе чыгарма булып тора;

11) җир кишәрлеген куллану рөхсәте җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән максатларга туры килми; территорияне планлаштыруның расланган проектына туры китереп линияле объект урнаштыру чыгарма булып тора;

12) җир кишәрлеген белдерелгән хокукларда бирү рөхсәт ителми;

13) мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеген ничек куллану рөхсәт ителүе билгеләнмәгән;

14) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелеп соралган җир кишәрлеге җирләрнең билгеле категорияләренә кертелмәгән;

15) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелеп соралган җир кишәрлеге бирү буенча алдан килештерелгән карар кабул ителгән, аны гамәлдә булу вакыты чыкмаган, җир кишәрлеген бирү турында әлеге карарда күрсәтелмәгән зат мөрәҗәгать итте;

16) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеген бирү максатлары  әлеге җир алынган максатларга туры килми; әлеге җир кишәрлегендә урнашкан күпфатирлы йорт тузган һәм сүтелергә яисә төзекләндерелергә тиеш дип танылу сәбәпле, җир кишәрлеге дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган булу чыгарма булып тора;

17) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлегенең чикләре “Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында” Федераль законга туры китереп ачыкланырга тиеш;

18) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы җир кишәрлегенең урнашу схемасына, территорияләрне

межалау проектына туры китереп ясалган булса да, аларда күрсәтелгәннән ун проценттан да күбрәккә артып китә.

**Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына 4 нче кушымта**

Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы

Гариза бирүче

Гариза бирүче (аның вәкиле) әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар беркетелгән

→ Мөрәҗәгать, документлар

Эш башкару бүлеге белгече

Документларны кабул итү, мөрәҗәгатьне һәм документларны теркәү, документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булу-булмавын тикшерү (Бүлек белгече белән берлектә) 1 көг

→ Документлар кабул итүдән баш тарту, кире кайтарылган мөрәҗәгать һәм документлар → Гариза бирүче

→ Кабул ителгән, теркәлгән, Бүлеккә юлланган документлар

Бүлек белгече

«ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында җир кишәрлеге бирү турында мөрәҗәгатьләр үтү битен» тутыра һәм ФСХ ТРИгә, Росреестр ТРИга, “ТР ФКП” ФДБга запрослар юллый
4 көн

→ ФСХ ТРИгә, Росреестрга ТРИгз, “ТР ФКП” ФДБга запрослар 5 көн

→ Министрлык запросларына ФСХИ ТРИ, Росреестр ТРИ, “ТР ФКП” ФДБ әзерләгән мәгълүматлар (документлар)

Бүлек белгече

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булуын тикшерә, арендага (милеккә) бирү турында карар проектын, аренда (сату-алу) шартнамәсе проектын, шартнамә проектына бергә теркәп җибәрелә торган хат яисә баш тарту турында сәбәпләре күрсәтелгән карар әзерли 5 көн

→ Арендага (милеккә) бирү турында карар проекты, аренда (сату-алу) шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар

Бүлек мөдире

Арендага (милеккә) бирү турында карар проектын, аренда (сату-алу) шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын карый һәм килештерә

→ Килештерелгән арендага (милеккә) бирү турында карар проекты, аренда (сату-алу) шартнамәсе проекты һәм шартнамә проектына бергә теркәп җибәрелә торган хатны яисә баш тарту турында карар

Идарә башлыгы

Арендага (милеккә) бирү турында карар проектын, аренда (сату-алу) шартнамәсе проектын һәм шартнамә проектына бергә теркәп җибәрелә торган хатны яисә баш тарту турында карар проектын карый һәм килештерә 3 көн

→ Килештерелгән арендага (милеккә) бирү турында карар проекты, аренда (сату-алу) шартнамәсе проекты һәм шартнамә проекты белән бергә теркәп җибәрелә торган хатны яисә баш тарту турында карар проекты

Бүлек белгече

Бүлек мөдире һәм идарә башлыгы белән килештерелгән арендага (милеккә) бирү турында карар проектын, аренда (сату-алу) шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын хокукый экспертизага юллый

Хокукый экспертиза юлланган арендага (милеккә) бирү турында карар проекты, аренда (сату-алу) шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар

Хокук идарәсе белгече

Арендага (милеккә) бирү турында карар проектына, аренда (сату-алу) шартнамәсе проектына яисә баш тарту турында карар проектына хокукый экспертиза (шул исәптән коррупциягә каршы экспертиза) ясый
2 көн

Килештерелгән арендага (милеккә) бирү турында карар проекты, аренда (сату-алу) шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты, яки арендага (милеккә) бирү турында карар проекты, аренда (сату-алу) шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проектына карата кисәтүләр булган очракта – хокук идарәсенең бәяләмәсе

Хокук идарәсе башлыгы

Арендага (милеккә) бирү турында карар проектын, аренда (сату-алу) шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карарны килештерә яки хокук идарәсенең бәяләмәсен имзалый
2 көн

Килештерелгән арендага (милеккә) бирү турында карар проекты, аренда (сату-алу) шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты

Арендага (милеккә) бирү турында карар проекты, аренда (сату-алу) шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проектына карата кисәтүләр булган очракта – хокук идарәсенең бәяләмәсе

Бүлек белгече

Хокук идарәсе бәяләмәсендә күрсәтелгән кимчелекләрне төзәтә һәм арендага (милеккә) бирү турында карар проекты, аренда (сату-алу) шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проектын килештерү өчен хокук идарәсенә юллый

Килештерү өчен хокук идарәсенә юлланган арендага (милеккә) бирү турында карар проекты, аренда (сату-алу) шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты

Хокук идарәсе башлыгы


Арендага (милеккә) бирү турында карар проекты, аренда (сату-алу) шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проектын килештерә
2 көн

Килештерелгән арендага (милеккә) бирү турында карар проекты, аренда (сату-алу) шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты

Бүлек белгече

Министрның беренче урынбасарына кул кую өчен арендага бирү турында карар проектын, аренда шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын юллый, яисә милеккә бирү турында карар проектын килештерү өчен юллый

Министрның беренче урынбасарына кул кую өчен юлланган арендага бирү турында карар проекты, аренда шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын, яисә килештерергә юлланган милеккә бирү турында карар проекты


Министрның беренче урынбасары
Министрның беренче урынбасары арендага бирү турында карар проектына, аренда шартнамәсе проектына яисә баш тарту турында карар проектына кул куя һәм теркәү өчен эш башкару бүлегенә юллый, милеккә бирү турында карар проектын килештерә һәм кул кую өчен министрга тапшыра
1 көн
Имзаланган җир кишәрлеген арендага бирү караы, аренда шартнамәсе проекты, аренда шартнамәсенә теркәп җибәрә торган хат проекты яисә баш тарту турында карар
Милеккә бирү турында килештерелгән карар проекты
Министр
Милеккә бирү турында карарны имзалый һәм министрның беренче урынбасарына юллый
1 көн
Министрның беренче урынбасары
Сату-алу шартнамәсе проектына һәм шартнамә проекты белән бергә теркәп җибәрелә торган хатны кул куя, милеккә бирү турында карар белән бергә эш башкару бүлегенә юллый
1 көн
Эш башкару бүлеге белгече
Җир кишәрлеген арендага яки милеккә бирү турында Министрлык карарын, аренда яки сату-алу шартнамәсен проекты белән бергә теркәп җибәрелә торган хатны, яисә баш тарту турындагы карар проектын терки һәм гариза бирүчегә юллый;
Җир кишәрлеген арендага яки милеккә бирү буенча Министрлык карарын Бүлеккә юллый
Гариза бирүчегә юлланган аренда (сату-алу) шартнамәсе проекты яисә баш тарту турындагы карар
Бүлеккә юлланган җир кишәрлеген арендага яки милеккә бирү буенча Министрлык карары
Гариза бирүче
Аренда (сату-алу) шартнамәсен имзалый
30 көн
Имзаланган аренда (сату-алу) шартнамәсе

Реестр бүлеге белгече,
Эш башкару бүлеге белгече

Бүлек белгече аренда (сату-алу) шартнамәсен терки, Эш башкару бүлеге белгече шартнамәне гариза бирүчегә юллый

Теркәлгән һәм гариза бирүчегә юлланган аренда (сату-алу) шартнамәсе

**Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына 2 нче кушымта**

Киңәш ителгән форма

Татарстан Республикасы Җир һәм
мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына

(кемнән)___________________________

Техник хатаны төзәтү турында гариза

_______________________________________________________________________________
(юридик зат атамасы, физик затның Ф.И.АИ, шәхси эшмәкәр)
_________________________________________________________________________,
(Ф.И.О., вәкилнең вазыйфасы)

_______________________________________________________ нигезендә эш итүче
(вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ)

Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәткәндә җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм җир кишәрлеген арендага (милеккә) бирү турында «____»_________ 20______ел. №________ шартнамәсенә тиешле үзгәртүләрне кертүне үтенә

Җир кишәрлеген арендага (милеккә) бирү турында
«____» ________ 20______г. №________ шартнамәдә
_______________________________________________________________ дип язылган
Дөрес белешмә:________________________________________________________
_____________________________________________________________________________

Түбәндәге документларны терким:
1.
2.
3.

Гариза бирүче (гариза бирүчеләр) турында белешмә:

Түбәндәге документларны беркетәм:
1.

2.
3.

Гариза бирүчеләр турында мәгълүмат (гариза бирүчеләр):

| | |
|---|---|
| Юридик зат өчен реквизитлар *(ОГРН, ИНН, адрес (урнашу урыны)*<br>Физик зат өчен (юридик затның вәкиле) паспорт мәгълүматы *(серия, номер, кем һәм кайчан биргән, подразделение коды, теркәлү адресы),*<br>Яшәү адресы (теркәлү адресы белән туры килмәгән очракта), ИНН | |
| | |
| | |
| | |
| Контакт өчен телефон, почта адресы һәм (яисә) электрон почта адресы | |
| Җир кишәрлеге турында белешмә | |
| Җир кишәрлеге әлеге документ һәм (яисә) әлеге проектта каралган объектларны урнаштыру өчен бирелгән очракта территориаль планлаштыру документын һәм (яисә) территорияне планлаштыру проектын раслау турында карарның реквизитлары | |
| Соралган җир кишәрлеге яңа барлыкка килгән яки аның чикләре әлеше карар нигезендә аныкланган очракта җир кишәрлеген бирү турында алдан килешенү карары реквизитлары | |
| Җир кишәрлеге зарурлык булып алынган җир кишәрлегенә алмашка бирелә икән, җир кишәрлегенең дәүләт ихтыяҗы өчен алынуы карары реквизитлары | |

“Персональ мәгълүматлар турында” 27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль законга туры китереп, мин 420043, ТР, Казан ш., Вишневский ур., 26 й. Адресында урнашкан Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына (оператор) персональ мәгълүматны эшкәртергә (әлеге гаризада күрсәтелгән персональ мәгълүматны җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, аныклауны (яңарту, үзгәртү), файдалану, тапшыру (тарату, бирү), блоклауны, бетерүне, юкка чыгаруны да кертеп, автоматлаштыру чаралары белән яки алардан башка кылынган гамәл (операция) яисә гамәлләр (операцияләр) белән эшкәртергә рөхсәт бирәм. Мәгълүматның дөреслеген раслыйм.

Әлеге килешү гариза имзаланган көннән башлап язма рәвештә килешүне кире соратып алган көнгә кадәр гамәлдә була.

Гариза бирүченең имзасы (_______№_________________________ышанычнамә буенча вәкил
_______________________________________/______________________/
(вәкилнең фамилия, имя, әтисе исеме, имзасы)

М.П. (мөһер булганда)

Гариза кабул ителде: "___"__________ 20__ г.
______/___________________/гаризаны алган белгечнең имзасы, фамилиясе, инициаллары)
)

**Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына**
**Кушымта (белешмәлек)**

Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр<br>Хамаев Азат Кыям улы | 221-40-00 | mzio@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары<br>Демидов Сергей Анатольевич | 221-40-01 | mzio@tatar.ru |
| Җир ресурслары идарәсе башлыгы<br>Миндубаева Гүзәл Эдуард кызы | 221-40-30 | Guzel.Mindubaeva@tatar.ru |
| Җир ресурслары идарәсенең Дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге мөдире Галиев Артур Ирек улы | 221-40-89 | Artur.Galiev@tatar.ru |
| Канцелярия эшләрен алып бару һәм контрольдә тоту бүлеге<br>Румянцева Гөлнур Нияз кызы | 221-40-81<br>221-40-83<br>221-40-79 | Gulnur.Rumyanceva@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе<br>Мостафин Айрат Рафинант улы | 264-77-15 | Ayrat.Mustafin@tatar.ru |
| Идарә башлыгы урынбасары<br>Аксанов Валерий Аркадьевич | 264-76-89 | Valeriy.Aksanov@tatar.ru |